| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

14.06.2019 Казан ш. № 1854-р

**Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт министрлыгының «Татарстан Республикасының Менделеевск муниципаль районы территориясендә бүлгеч челтәрнең саклау зонасы чикләрен билгеләү турында» 17.04.2019 № 1236-р карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карар чыгарды:

1. Территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка туры китереп Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт министрлыгының «Татарстан Республикасының Менделеевск муниципаль районы территориясендә бүлгеч челтәрнең саклау зонасы чикләрен билгеләү турында» 17.04.2019 № 1236-р карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Әгерҗе, Алабуга, Мамадыш, Менделеевск муниципаль районнары, «Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре»

муниципаль берәмлеге территориясендә бүлгеч челтәрнең саклау зонасы чикләрен билгеләү турында»

пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасының Әгерҗе, Алабуга, Мамадыш, Менделеевск муниципаль районнары, «Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендәге ЭПУ «Елабугагаз»ның бүлгеч челтәрнең (газүткәргеч) саклау зонасы чикләрен территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп расларга.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**